КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 14 июнь г.Казань № 718

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 – 2026 елларга Татарстан Республикасында аутистик спектрдагы бозылышлары һәм башка менталь бозылышлары булган кешеләргә комплекслы булышлык күрсәтеп тору концепциясен раслау турында» 2022 ел, 14 ноябрь, 1208 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 – 2026 елларга Татарстан Республикасында аутистик спектрдагы бозылышлары һәм башка менталь бозылышлары булган кешеләргә комплекслы булышлык күрсәтеп тору концепциясен раслау турында» 2022 ел, 14 ноябрь, 1208 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 11 февраль, 139 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган 2022 – 2026 елларга Татарстан Республикасында аутистик спектрдагы бозылышлары һәм башка менталь бозылышлары булган кешеләргә комплекслы булышлык күрсәтеп тору концепциясен тормышка ашыру чаралары планында:

1.3 пунктның 12 графасында «1 500,0» саннарын «3 960,0» саннарына алмаштырырга;

«1 бүлек буенча барлыгы» юлының 12 графасында «9 765,0» саннарын» 12 225,0» саннарына алмаштырырга;

6.2 пунктның 12 графасында «5 000,0» саннарын «2 540,0» саннарына алмаштырырга;

«6 бүлек буенча барлыгы» юлының 12 графасында «5 000,0» саннарын «2 540,0» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2022 – 2026 елларга Татарстан Республикасында аутистик спектрдагы бозылышлары һәм башка менталь бозылышлары булган

кешеләргә комплекслы булышлык күрсәтеп тору концепциясен тормышка ашыру буенча ведомствоара эшче төркем составында:

эшче төркем составыннан Ж.В.Халтуринаны чыгарырга;

эшче төркем составына Заһретдинов Гадел Линнар улын, «Үз мәнфәгатьләрен чагылдыруга мохтаҗ булган ментальь һәм башка бозылулары белән инвалид балаларның һәм 18 яшьтән өлкәнрәк инвалидларның ата-аналарының бөтенроссия оешмасы» бөтенроссия иҗтимагый оешмасының төбәк бүлеге рәисен кертергә (килешү буенча);

Мостафина Софья Альфредовна вазыйфасының исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министрының беренче урынбасары».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин